КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 5 февраль № 71

г. Казань

«Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисадый саммитын үткәрү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисадый саммиты турында» 2015 ел, 11 декабрь, ПУ-1193 нче Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

«Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисадый саммиты турындагы нигезләмәне;

«Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисадый саммитын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\71.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 5 февраль, 71 нче карары белән расланды

«Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit»
халыкара икътисадый саммиты турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисадый саммитын (алга таба – Саммит) үткәрү максатын, бурычларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Саммит ел саен Казан шәһәрендә үткәрелә.

2. Саммитның максаты һәм бурычлары

2.1. Саммитны үткәрү максаты – Татарстан Республикасының һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни элемтәләрен ныгыту, шулай ук Россия Федерациясендә ислам финанс системасы институтларын үстерүгә булышлык күрсәтү.

2.2. Саммитны үткәрү бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

2.2.1. Саммитта катнашучылар арасындагы халыкара икътисадый мөнәсәбәтләрне үстерүнең стратегик перспективаларын билгеләүдә тәкъдимнәр әзерләү.

2.2.2. Россия Федерациясе, Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге һәм Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең эшмәкәрлек эшчәнлегендә катнашучыларның үзара багланышларын ныгытуга булышлык күрсәтү.

2.2.3. Әйдәп баручы дөньяви экспертларны агымдагы икътисадый һәм сәяси мәсьәләләр буенча бергәләп фикер алышуга җәлеп итү.

2.2.4. Ислам финанс системасы институтлары эшләве һәм Россия Федерациясе икътисады өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүгә йөз тоткан тәкъдимнәр һәм закон чыгару инициативалары эшләү.

2.2.5. Финанс проектларын гамәлгә ашыру буенча уңышлы тәҗрибә алышуны оештыру.

2.2.6. Татарстан Республикасы икътисадына туры чит ил инвестицияләрен җәлеп итү.

3. Саммитны оештыру

3.1. Саммитны әзерләү һәм үткәрү өчен Саммитны оештыру комитеты төзелә.

3.2. Саммитны оештыру комитеты:

3.2.1. Саммитны әзерләү һәм үткәрү белән оператив җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

3.2.2. Саммит программасынраслый;

3.2.3. Саммит чараларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуга булышлык күрсәтә;

3.2.4. Саммитны әзерләү һәм үткәрү чорында Саммитның реклама кампаниясен гамәлгә ашыра;

3.2.5. Оештыру мәсьәләләрен һәм Саммитны финанслар белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итә, шул исәптән Саммитта катнашучыларның оештыру кертемнәре күләмен раслый;

3.2.6. Ел саен, Саммитны үткәрү елы алдыннан килгән елның 31 декабренә кадәр, Татарстан Республикасы Мигнистрлар Кабинетына Саммитны киләсе елда үткәрү вакыты һәм урыны турында тәкъдимнәр кертә;

3.2.7. Әлеге Нигезләмә нигезендә башка вәкаләтләр башкара.

3.3. Саммит операторы вазыйфаларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләтләр бирелгән оешма башкара.

3.4. Саммит операторы:

3.4.1. Саммитны оештыру һәм үткәрү чараларын гамәлгә ашыра;

3.4.2. Саммитта катнашу өчен заявкалар кабул итүне, катнашучыларның оештыру кертемнәрен җыюны гамәлгә ашыра.

## 4. Саммитны үткәрү вакытлары һәм урыны

4.1. Саммитны үткәрү вакытлары һәм урыны ел саен Саммитны оештыру комитеты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

4.2. Саммитны үткәрү урыны, вакытлары турында мәгълүмат Саммитны оештыру комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

## 5. Саммитны үткәрү шартлары һәм тәртибе

5.1. Физик һәм юридик, шул исәптән чит илдән килгән затлар, шулай ук дәүләтләр һәм халыкара оешмалар вәкилләре Саммитта катнашучылар була ала.

5.2. Саммитта катнашу өчен заявка бирүче Саммитны оештыру комитеты билгеләгән вакытта, әмма Саммитны үткәрү көненә кадәр 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Саммитны оештыру комитеты билгеләгән форма буенча заявка һәм Саммит операторының исәп хисабына оештыру кертемен түләгәнне раслый торган түләү документы күчермәсен Саммит операторына кертә.

5.3. Саммит операторы заявка бирүчене Саммитта катнашуга кертү турында Саммитны оештыру комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта карар кабул итә.

## 6. Саммитны финанслар белән тәэмин итү

6.1. Саммитны финанслау Саммитны оештыру комитеты тарафыннан күләме билгеләнә торган катнашучыларның оештыру кертемнәре һәм законнар белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

6.2. Саммит операторы Саммитны оештыру комитеты күрсәтмәләре буенча оештыру кертеме акчасын Саммитны оештыру-методик, техник яктан һәм мәгълүмат-реклама белән тәэмин итүгә, каталоглар һәм башка полиграфия материаллары чыгаруга, Саммит чараларын һәм акцияләрен оештыруга һәм үткәрүгә, Саммитның максатлары нигезендә катнашучыларның мәнфәгатьләрендә булган проектларны үстерүгә һәм тормышка ашыруга тота.

Саммит операторы Саммитны мәгълүмати тәэмин итү, оештыру чыгымнарын һәм башка чыгымнарны каплау өчен иганәчеләр ярдәме рәвешендә законнар нигезендә өстәмә акча җәлеп итәргә хокуклы.

---

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 5 февраль, 71 нче карары белән расланды

**«Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit» халыкара икътисадый саммитын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Халиков Илдар Шәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры, оештыру комитеты рәисе |
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе, оештыру комитеты секретаре |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Агеев Шамил Рәхим улы | Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Айдельдинов Айнур Тәүфыйк улы | «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Вафин Адел Юныс улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Вахитов Радик Рәфыйк улы | Россия Федерациясе Чит ил эшләре министрлыгының Казан шәһәрендәге вәкиле (килешү буенча) |
| Гайнетдинов Ренат Вагыйз улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Галәвов Гадел Әсфән улы | Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәчесе урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гәрәев Зөфәр Фәнил улы | «Ак Барс» банкы гавами акционерлык җәмгыяте идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Гыйматдинов Радик Рөстәм улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Зарипов Айрат Ринат улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Здунов Артём Алексеевич | Татарстан Республикасы икътисад министры |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Мавликов Альберт Вәзил улы | Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсенә караган Татарстан таможнясы башлыгы (килешү буенча) |
| Метшин Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов Фәргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча) (килешү буенча) |
| Ногманов Адел Фуат улы | «Татарстан Республикасын үстерү корпорациясе» ачык акционерлык җәмгыяте директоры (килешү буенча) |
| Нәфыйгин Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Носов Игорь Николаевич | «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Сафин Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Сибагатуллин Айрат Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |

| | |
|---|---|
| Старостин Алексей Александрович | «Казан» халыкара аэропорты» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Тарабрин Олег Юрьевич | «Казан-аэропорт» тикшерү-үткәрү пункты башлыгы (килешү буенча) |
| Фәйзрәхманов Марат Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Казначылык департаменты директоры |
| Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улы | Россия Федерациясе Үзәк банкының Идел-Нократ баш идарәсе башлыгы урынбасары – Россия Федерациясе Үзәк банкы Идел-Нократ баш идарәсенең Татарстан Республикасы буенча милли банкы – Бүлек идарәчесе (килешү буенча) |
| Шаһивәлиев Тимур Наил улы | «Алабуга» махсус икътисадый зонасы» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры. |

_______________________________